РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
17.02.2023

КАРАР
№6

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 2021 елның 29 сентябрендә кабул ителгән №22 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Саба районы Прокуратурасының 09.02.2023 №02-08-02-2023/201-23-20920031 протесты һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 04.11.2022 №427-ФЗ Федераль законның «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 26.12.2008 елгы №294-ФЗ Федераль законның 14, 18 статьяларына (алга таба Закон), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 04.02.2023 №УП-68 Указына таянып, Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында” 29.09.2021 елны №22 карары белән расланган Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.9.1. пунктының 5) пунктчасында «Президент» сүзен Башлык (Рәис) сүзенә алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 1.9. пункты 13) пунктчасын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«13) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының, муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары, тикшерелергә тиешле затларны җитәкче, бүтән вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча административ регламентлар яисә контроль чараларын үткәрүне җайга сала торган башка норматив хокукый актлар һәм юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген башкарганда файдаланыла торган объектларда уздыру тәртибе белән таныштырырга тиеш.»;

1.3. Нигезләмәнең 5.11. пунктының 5.11.1. пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге өченче абзац белән тулыландырырга:

«Күчмә тикшерү үткәрелә башлаганчы, җитәкче, бүтән вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча, шулар нигезендә тикшерү үткәрелгәндә, аларны муниципаль органның административ регламент нигезләмәләре яисә башка норматив хокукый акт (шундый административ регламент яки башка норматив хокукый акт булганда) белән таныштырырга;”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы А.К.Сафин